Министерство образования и науки Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Дворец творчества детей и молодежи имени И.Х. Садыкова»
Нижнекамского муниципального района
Республики Татарстан

ПРИНЯТА
на заседании педагогического совета
МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
Протокол № 4
от «23» апреля 2021 г.

УТВЕРЖДАЮ
Директор МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
_____Р.Н. Салихзянов
Приказ № 96
от «23» апреля 2021 г.

ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА «ЛИТЕРАТУРНО-ДРАМАТИЧЕСКИЙ»

Направленность: художественная
Возраст учащихся: 10-18 лет
Срок реализации: 4 года (792 часов)

Составитель:
Нуруллина Расима Фарутдиновна,
педагог дополнительного образования

Нижнекамск, 2021 год

Укыту программасының информацион картасы

1	**Белем бирү оешмасы**	Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае”
2	**Программаның тулы исеме**	Әдәби - драматик
3	**Программаның юнәлеше**	Сәнгати
4	**Программаны төзүчеләр турында мәгълүмат**	
4.1	Ф.И.О.	Нуруллина Р.Ф., югары категорияле өстәмә белем бирү педагогы
5	**Программа турында мәгълүмат:**	
5.1	гамәлгә ашыру вакыты	4 ел
5.2	укучыларның яше	10-18 яшькә кадәр
5.3	программага характеристика: - программаның тибы - программаның төре - программаны проектлау принциплары - укыту процессын оештыру эчтәлеге формасы	Үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы модификацияле дәрес
5.4	программаның максаты	укучыларны татар әдәбияты нигезләре, җыр – музыка сәнгате, халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру, сәнгать әсәрләре аша – тормышка, дөньяга карашларын формалаштыру.
6.	**Белем бирү программасының формалары һәм алымнары**	Балалар берләшмәсе. проблемалы-эзләү ысуллары, мөстәкыйль һәм гамәли эшләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр
7.	**Нәтиҗәлелекне мониторинглау формалары**	тестлар, биремнәр, кичәләр, бәйгеләр, реферат яклау
8.	**Программаның нәтиҗәлелеген тормышка ашыру**	
9.	**Программаны раслау һәм соңгы үзгәртү датасы**	23.04.2021
10.	**Рецензентлар**	Зиновьева Ф.М. – бүлек мөдире

Эчтәлек

1. Аңлатма …….....4-8
2. Укыту планы
1нче ел…….....8-9
2нче ел.....11-12
3нче ел.....13-14
4нче ел.....15-16
3. Программаның эчтәлеге
1нче ел…….....9-11
2нче ел.....12-13
3нче ел.....14-15
4нче ел.....16-17
4. Программаның методик һәм материаль-техник яктан тәэмин ителеше
.....17-22
5. Кулланма әсбаплар.....22-23
6. Кушымта.....23-48

АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Әдәби - драматик» программа сәнгать юнәлешендәге программа.

Матур әдәбият - сәнгатьнең бер төре. Ул безне гомер буе озата, яшәргә һәм кеше булырга өйрәтә. Бала теле ачылганнан алып сөйләшә башлый. Ләкин ничек сөйләшә, сөйләме аның фикерен, уй-хыялларын башкаларга җиткерә аламы?

Туган тел – Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торган бөек, изге сүз. Телдә халыкның Милли психолгиясе, характеры, фикерләү һәм ижат үзәнчәлекләре ачыла, тарихы һәм мәдәниятен чагылыш таба. Туган телне яхшы белү, саклау һәм үстерү халыкның рухи хәзинәләрең, мәдәнияте, тарихын, авыз ижатын киләчәк буыннар өчен саклап калу дигән сүз.

Бала теле ачылганнан алып сөйләшә башлый. Ләкин ничек сөйләшә, сөйләме аның фикерен, уй-хыялларын башкаларга җиткерә аламы? Аның рухи дөньясы көче-сәләте һәм матулыгы сөйләмендә, язуында күренәме? Бу изге төшенгәләрне үстерү, баету өчен нәрсә эшләргә?

Әдәби – драматик берләшмәнең төп функциясе шушы сорауларга җавап эзләүдән гыйбарәт булган ижади процесс

Программа төп норматив документлар нигезендә төзелде:

- Программа “Россия Федерациясендә мәгариф турында 29.12.2012ел, №273 – ФЗ Федераль законның 12 статьясы, РФ дә балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе (РФ Хөкүмәтенең 2014 елның сентябрендәге 1726 – р номерлы күрсәтмәсе) нигезендә эшләнде;
- Россия мәгариф һәм фән министрлыгының балаларга тәрбия һәм социаль яшләр ярдәм күрсәтү буенча яшләр сәясәте Департаменты хатына кушымта - “Балаларга өстәмә белем бирү программаларына үрнәк таләпләр”12.2006ел, №06-1844;
- “Рекомендацияләр җибәрү турында” РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.11.2015ел, №09-3242 хаты (“Гомуми үсештәге өстәмә программаларны проектлау буенча методик рекомендацияләр”;
- «Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру турында” 14.12.2015ел, №09-3564 РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Хаты белән (“дәрестән ты эшчәнлекне оештыру һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча методик рекомендацияләр”);•
- Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән Министрлыгының «Өстәмә гомумбелем бирү программаларын оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау » турындагы 2018 ел 9 ноябрендагы 196 нчы номерлы боерыгы;
- Санитар-¬эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормалар. СанПиН 2.4.4.3172-14 (Россия Юстиция миниистрлыгында 20 август 2014 ел N 33660 теркәлгән);
- “Рекомендацияләр җибәрү турында” Россия мәгариф һәм фән Министрлыгының 18.11.2015ел №3242 хаты “Гомуми үсештәге өстәмә программаларны проектлау буенча методик рекомендацияләр”;

- Заманча өстәмә белем бирү (гомуми үсеш алган) программаларын проектлау буенча Методик тәкүдимнәр/ Сост. Идрисов Р.А., Владимирова Ю.Ю., Ярмакаева С.А. – Казан:ДБО “РЦВР”, 2017;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “И.Х.Садыйков исемендәге Балалар һәм яшләр иҗаты сарае” уставы.

Программаның актуальлеге.

Баланың аз укуы. Бүгенге заман баласы күбрәк үз вакытын телевизор алдында, интернет челтәрендә, планшет тотып үткәрергә ярата. Ә бу исә үз чиратында танып – белү активлыгын сүндерә, алга таба омтылу эшчәнлеген куып чыгара.

Бала үз иптәшләре белән аз аралаша. Укучыларның күзгә – күз аралашуының бик түбән дәрәҗәдә булуы. Алар буш вакытлары булды исә, кулларына кәрәзле телефон алып, бөтен игътибарын шунда юнәлтә, шулай ук смс, интернетта утыру һәм язу, аралашуны ныкиметә.

Башка программалардан үзгәлеге.

Өстәмә белем бирү программасы буларак, ул мәктәп программасын җиңел үзләштерүче балалар өчен дә, программаны авыр үзләштерүчеләр өчен дә исәпләнгән. Программаның өстенлеге шунда – ул рус телле балаларга татар әдәби телен, сүз сәнгате серләрен өйрәтү аспектларын да күзаллый.

Программаны тормышка ашырганда мәгълумати һәм компьютер технологияләре, шулай ук дистанцион укыту формалары актав куланыла. Алынган белемнәрне ныгыту, гамәли күнекмәләрне камилләштерү өчен сайтлар белән дистанцион хезмәттәшлек алып барыла:

1. https//tatarica.org/ru/razdely/nauka/nauchnye-obshestya/obshestvo-izucheniya-tatarctana;
2. Образовательная платформа «ZOOM»;
3. tatarmultfilm.ru;
4. kinodeti.tv;
5. m.vk.com/teatralts;
6. ***posleurokov.ru***

ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ

Укучыларны татар әдәбияты нигезләре, җыр – музыка сәнгате, халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру, сәнгать әсәрләре аша – тормышка, дөньяга карашларын формалаштыру.

БУРЫЧЛАРЫ

Белем бирү бурычы: сөйләм культурасын үстерү, әдәби тел нормаларын белергә, сузык һәм тартык авазларның артикуляция үзенчәлекләрен аерырга, дикция өстендә һәрдаим эшләргә өйрәтү;

Үстерү бурычы: театр сәнгатен тирәннән күзаллауны үстерү, ораторлык сәнгате турында гомуми белешмә бирү, күз һәм акыл хәтерен яхшырту.

Тәрбия бирү бурычы: балаларда рухи хәзинәбезгә ихтирам уяту, шәфкатьлелек, инсафлылык элементлары тәрбияләү, балаларда дуслык, татулык,

бер-берсен хөрмәт итү хисләрен тәрбияләү, коллективта психологик-эмоциональ халәтне дөрес табарга өйрәтү.

Программаны тормышка ашыруда катнашучы балаларның яше:

Программа 1- 11сыйныфта укучы 7-18 яшьтәге балалар өчен тәкъдим ителә. Әдәби - драматик берләшмәгә теләк белән килгән кызлар һәм малайлар алына.

Программның күләме 792 *сәгать.* Программа 4 ел укытылуга язылган. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла. Беренче ел укыту сәгате – 144 сәгать, икенче, өченче, дүртенче ел укыту - 216 сәгать тәшкил итә.

Дәресне оештыру формалары.

Прграммада укыту формасы буенча эш фронталь, индивидуаль, парлап-парлап, звенолап һәм группалап оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш.

Фронталь формада укыту материалны бөтен коллективка бирү юлы булса, звенолап һәм төркем белән эшләү юлында укучыларга сәләтләрен ачарга, бер-берсенең ярдәмен тоярга һәр конкрет этапта мөмкинлекләр туа.

Укучыларның укыту һәм тәрбия ихтияҗларын үзенчәлекле итү өчен төркемнәр һәм төркемчекләр белән эшләү тәкъдим ителә (баланың яше һәм берләшмәдә эшләү тәҗрибәсе күздә тотыла). Индивидуаль форма укучының мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнүен искәртә. Монда педагог ярдәме белән баланың эшчәнлеге арта, ул мөстәкыль эшләргә өйрәнә. Дәресләрнең эчтәлеге дифференциаль яктан балалар һәм яшүсмерләрнең яшен исәптә тотып билгеләнә. Аларда балаларның индивидуаль ижади үсеше өчен барлык шартлар чагыла. Теоретик һәм практик дәресләр, күрсәтмә материаллар (этголингвистик материаллар, таблицалар, схемалар, альбомнар, карточкалар, видеосюжетлар, презентацияләр)

- типовой дәресләр (үз эченә теоретик нигез белән танышу һәм теоретик нигезне ныгыту өчен кирәк булган күнегү һәм уеннарны ала);
- ижади дәресләр (презентацияләр, хикәяләр, проектлар төзү, видео язмалар булдыру һ.б.);
- практик дәресләр ;
- видеоматериаллар карау;
- сюжетлы-уенлы һәм бәйге программалары;
- спектакльләр куелышлары.

Программаны үзләштерү вакыты

Программа дүрт ел укытылуга язылган. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла. Беренче ел укытылучы балалар саны – 15, икенче, өченче, дүртенче ел укытылучылар саны – 10.

Дәрес режимы

Программа буенча башлангыч сыйныф укучылары шөгыльләнә ала. Беренче ел укытылучы балалар атнага 2 көн 2шәр сәгать, икенче, өченче, дүртенче ел укытылучы балалар атнага 2 көн 3әр сәгать белем алалар. Укыту укучылар сәламәтлегенә зыян килми торган җылы, якты һәм уңайлы бүлмәләрдә алып барыла. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла. Беренче ел укытылучы

балалар саны – 15, икенче ел укытылучылар саны - 12, өченче, дүртенче ел укытылучылар саны – 10.

Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

Предмед күрсәткечләре.

Беренче ел укыту азагында укучы
белергә тиеш:
-сәхнә теле нормаларын аңлау;
-авазлар артикуляциясенең үзенчәлекләрен тоя белү,
-сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен ныклап үзләштерү;
Икенче ел укыту азагында укучы
белергә тиеш:
-бирелгән роль өстендә эшләү;
-төрле характердагы геройларның күңел халәтләрен күрсәтү;
- әсәрдәге конфликтны, төрле фактларны аңлата һәм дөреслекне исбатлый белү;

Өченче укыту ахырында укучы
белергә тиеш:
-сәхнә әсәрләренә лингвистик анализ ясый белү;
-үз тәкъдимнәрен һәм идеяләрен бирү ;
-бирелгән роль өстендә эшләүнең нечкәлекләрен белү, камилеккә ирешүдә ихтыяр көчен күрсәтү;
-татар театрының үзенчәлекләрен, режиссерлар эшчәнлеге нидән гыйбарәт икәнен тирәннән аңлау;
-сөйләм теле белән язма тел арасында булган аермалыкларны тоемлау;
- диалог, монолог төзүнең үзенчәлекләрен аеру;
4 нче ел укуыту ахырында укучы
белергә тиеш:
-публицистик стильдә үз фикерләрен матурлап яза алу;
-төрле өлкәләрдә, төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең гореф – гадәтләрен, аларның авыз иҗаты үрнәкләрен белү;
күнекмәләр:
-өйрәнелә торган сәхнә әсәрләрен тулысы белән анализлау;
- сәхнәдә үзеңне иркен тоту, тамашачы каршында дулкынламый чыгыш ясау;
-фәнни - гамәли конференцияләрдә чыгышлар ясау күнекмәләрен тулысынча үзләштерү;
Шәхси һәм предметара дәрәҗәдә:
- куелган проблемаланы табу һәм чишә белү;
-активлык күрсәтү,
-үз тәкъдимнәрен һәм идеяләрен бирү,
-куелган максатка ирешүдә ихтыяр көчен күрсәтү,
- төркемдә эшләү күнекмәләренә ия булу;
- сәламәтлекнең көчен һәм бәясен аңлау;
-өстәмә материаллар, төрле чыганаклар белән эшләү;
- уңышка ирешү юлларын кузаллау;
-эш нәтиҗәләрен күрсәтә белү;

-фикерләү сәләтләрен үстерү,
алынган белем – мәгълүматларны камилләштерү, киңәйтү, бер системага салу, башка фәннәрдә дә куллана белү;
- хезмәттәшлек итүнең серләрен белү, коммуникатив күнекмәләргә ирешү;
- тормышта үзеңнең тоткан урыныңны билгеләү, актив позициягә омтылу.

Программаны үзләштерү коммуникатив һәм гуманлылык кебек асыл сыйфатларга ия булган, халкыбыз традицияләрен хөрмәт итүче, дөньяны камил итеп танып белергә омтылучан, мәдәниятыбызны баетырга сәләтле, һәрдаим үз өстендә эшләүче максатчан, актив иҗади шәхес формалаштыра.

Программаны тормышка ашыруны тәэмин итүче нәтиҗә формалары

Укыту процессы түбәндәге тикшерү ысулларын күздә тота:

а) кереш - әңгәмә, сораштыру, тестлар эшләү (уку елы башында үткәрелә, үткән темалар буенча белем һәм күнекмәләрне ныгыту өчен);

б) агымдагы – практик эш, биремнәр, төрле кичәләрдә катнашу, район, республика күләмендәге бәйгеләрдә, фестивальләрдә, конкурсларда чыгыш ясау;

в) арадаш тикшерү – тестлар эшләү (программадагы билгеле бер бүлекне узганнан соң);

д) йомгаклау (уку-укыту программасын бетергәннән соң) – йомгаклау чыгышы.

Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Әдәби-драматик" өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү турында таныклык бирелә.

1 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

№	Тема	Барлык сәгать	Теория	Практика	Аттестация формалары
1.	Кереш өлеш	*2*	*2*	-	Әңгәмә, сораштыру
2.	Телләр белгән – илләр гизгән. Сүзләр дөньясында. Тел бизәкләре - фразеологизмнар	10	5	5	Аралашу
3.	Тарихларда җуелмас сукмак (халкыбызның олуг галимнәре Г. Ибраһимов)	8	5	3	
4.	18 гасырдагы татар мәдрәсәләре (Мәгариф тарихыннан). Бабаларыбыз эзеннән(шәҗәрәләр).	8	4	4	Тест
5.	Болгарым – горурлыгым. Идел буе татарлары	8	4	4	Мини - тест
6.	Шигърият - гөлбакча	20	5	15	Иҗади бәйге
7.	Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльлләнү	16	-	16	Мини - тест

8.	19 Гасыр әдәбияты. XX йөз башы әдәбияты Г. Тукай иҗаты	14	5	9	Үзлектән эш
9.	Халкыбызның жыр, музыка сәнгате. Опера, театр сәнгате	38	16	22	Иҗади эш
10.	Татар балалар фольклоры. Татар халык авыз иҗаты	18	5	13	Тест
12	Йомгаклау	2	2		иҗади эш
	Барлык сәгать:	144	67	77	

1 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

1 тема. Түгәрәкнең планы, максаты белән танышу. Хезмәт иминлеге кагыйдәләрен өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

2 тема. Телләр белгән – илләр гизгән. Сүзләр дөньясында. Тел бизәкләре – фразеологизмнар.

Максат. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен, сүзлекләр белә аңлау, сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен ныгыту.

Җиһазлау. “Идел”, “Казан”, “Мирас”, “Гасырлар авазы” журналары,аңлатмалы, , фразеологик этимологик, тәрҗемәи сүзлекләр, энциклопедияләр, альбомнар, аудио – видеокассеталар, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

Татар милләтенең күренекле шәхесләре (папкалардагы материаллар).

3 тема. Тарихларда җуелмас сукмак (халкыбызның олуг галимнәре Г. Ибраһимов).

Максат. Олуг галим Г. Ибраһимов иҗаты һәм тормыш юлы белән якыннан танышу, язучы итаты буенча презентация ясау.

Җиһазлау. Татар әдәбияты тарихы 1 – 5 том. – Казан, 1999. – 2003., Мирас”, “Казан”, «Мәгариф» журналлары, альбомнар, аудио – видеокассеталар, автор җыентыклары.

4 тема. 18 гасырдагы татар мәдрәсәләре (Мәгариф тарихыннан). Бабаларыбыз эзеннән (шәҗәрәләр).

Максат.Татар мәдрәсәләре «Иж – Буби», «Мөхәммәдия” эшчәнлеге белән, алардан укып чыккан күренкле шәхесләр белән танышу (Мәгариф тарихыннан). Шәҗәрәләр турында төрле материалларны өйрәнү.

Җиһазлау. “Гасырлар авазы”, “ Мәгариф”, “Мирас” журналлары №5, 6. 7 – 2000ел.Татар әдәбияты тарихы 1 – 5 том. – Казан, 1999. – 2003. , альбомнар, аудио – видеокассеталар, мәкаләләр, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон. Юл йөрү кагыйдәләре.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева,

С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

5 тема. Болгарым – горурлыгым. Идел буе татарлары тормышы, көнкүреше һәм бәйрәмнәре.

Максат. Болгар ханлыгы чоры,Биләр – Киев багланышлары материалларын өйрәнү, Идел буе татарлары томыш – көнкүрешенә кагылышлы кызыклы мәгълүматлар белән танышу. Сөмбелә. Нәүрүз, Сабантуй һ.б. бәйрәмнәр.

Җиһазлау. "Гасырлар авазы", "Мирас", "Казан", «Мәгариф» журналлары, темага кагылышлы альбомнар, аудио – видеокассеталар, мәкаләләр, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

6 тема. Шигърият – гөлбакча.

*Максат.*Татар шигъриятенең үзенчәлекләре. Шигырь төзелеше. Ритмик яңгыраш. Озын, кыска үлчәмдәге шигырьләр.

Җиһазлау. «Мирас", "Казан", «Мәгариф» журналлары, альбомнар, аудио – видеокассеталар, шагыйрьлрнең җыентыклары, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

7 тема. Иҗади күнегүләр. Тәрҗемә эше белән шөгыльлләнү.

Максат. Лирик шигырьләрне прозага әйләндерү.

Эпитет, гипербола, метонимия, метафора, сынландыру кебек сурәтләү чараларыннаң әһәмиятен ассоциатив формаларда әдәби әсәрләрдә кулланышын аңлау һәм кулланырга өйрәтү.

Җиһазлау. рус телендәге җыр, хикәя, шигырь, әкият һәм очеркларны стилистик яктан дөрес итеп татар теленә тәрҗемә иткән үрнәкләр. Сүзлекләр, энцилопедияләр, тематик календарьлар, журналлар, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

8 тема. XIX гасыр әдәбияты. XX йөз башы әдәбияты.

Җиһазлау. Бу чорда яшәп иҗат иткән язучылар турында, аларның эшчәнлегенә кагылышлы мәкаләләр, альбомнар, аудио – видеокассеталар. «Моңлы саз чыңнары» җыентыгы, Г. Тукайның шигырьләр китабы, папкага кулланган мәкальләр, рәсемнәр, Казан, «Мирас», «Гасырлар авызы» журналлары, Г. Тукай портреты «Су анасы», «Шүрәле» балетыннан төсле иллюстацияләр магнитафон, кассеталар«Тукай в контексте мировой литературы» статья из журнала «Татарстан». «Тукай – солнце татарской поэзии» - стенд.

9 тема. Халкыбызның жыр, музыка сәнгате. Театр сәнгате.

Максат. Халкыбызның жыр, музыка сәнгате. Театр сәнгате белән тирәннән танышу.

Җиһазлау. «В мире татарской музыки», Татар халык җырлары" китабы, аудио һәм видеокассеталар, «Казан», «Музыкальная жизнь», «Музыка и время» журналлары, фотографияләр, рәсемнәр, «Композиторы Татарстана» папкасы, Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин театры, Әлмәт театры, Балалар театры "Әкият"альбомнары, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон, "Җәлил" операсы

10 тема. Татар балалар фольклоры.

*Максат.*Багу поэзиясе, Күңел ачу фольклоры, Уен фольклоры. Сынамышлар, Әйтешләр. Алдавычлар. Эндәшләр. Юаткычлар. Мавыктыргычлар белән танышу, аларны өйрәнү.

Җиһазлау. «Татар балалар фольклоры», Татар энциклопедиясе, карточкалар, папкаларга тупланган материаллар, фотографияләр, рәсемнәр «Салават күпере», «Сабыйга», «Ялкын», «Сабантуй» газета һәм журналлары, ноутбук, интерактив такта, видеомагнитофон.

11 тема: йомгаклау дәресе.

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Нинди уңышларга иреште к. Фикерләр алышу. Алдагы уку елына планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау.

2 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

№	Тема	Барлык сәгать	Теория	Практика	Аттестация формалары
1.	Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре бәләнтанышу	3	3	-	тест
2.	Татар милләтенең үзенчәлекләре	3	2	1	аралашу
3.	Балалар фольклоры	15	5	10	Мини - тест
4.	Иҗади күнегүләр Тәрҗемә эше белән шөгыльләнү	36	2	38	Үзлектән эш
5.	К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге	6	4	-	Карточкалар белән эш
6.	Тукай һәм музыка	18	4	10	Иҗади бәйге
7.	Чит өлкәләрдә һәм чит илләрдә яшәүче татар зыялылары , галимнәре	12	10	4	әңгәмә
8.	Татар халык авыз иҗаты	48	6	42	тест
9.	Идел буенда яшәүче халыкларның теле һәм мәдәнияты (башкортлар, чуашлар, марилар, удмуртлар)	36	10	24	Карточкалар белән эш
10.	Халкыбызның җыр – музыка сәнгате	36	10	26	Иҗади эш, тест сораулары
11.	Йомгаклау	2	2		иҗади эш

	Барлык сәгать:	216	58	158	

2 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

1 тема. Түгәрәкнең планы, максаты белән танышу.Хезмәт иминлеге кагыйдәләрен өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

2 тема. Татар милләтенең үзенчәлекләре (билгеләре, Милли сыйфатлары милли үзаң.

Җиһазлау. Абдуллин «Милләт язмышы» уйланулар китабы

Казан, мирас, Гасырлар авазы журналары

Татар милләтенең күренекле шәхесләре (папкаларындагы материаллар)

3 тема. Балалар фольклоры Тизәйткечләр, шаярулар,

Максат. Сөрән салу уеннары, табышмаклар, Ш. Галиев иҗаты белән танышу. Түгәрәккә йөрүче балаларның тизәйткечләрдән рифмадаш сүзләр табып үз шигырьләрен иҗат итүгә юнәлеш бирү, ритмик яңгыраш өстендә эшләү.

Җиһазлау “Балалар фольклоры “китабы, газеталардан материаллар журналлар

4 тема. Иҗади күңегүләр. Лирик шигырьләрне прозага чәчмә формага әйләндерү, оригинал белән чагыштырып чыгаруга өйрәнү.

*Максат.*Эпитет, гипербола, метонимия, метафора, сыйнландыру кебек сурәтләү чараларыннаң әһәмиятен ассоциатив формаларда әдәби әсәрләрдә кулланышын аңлау һәм кулланырга өйрәтү.

Җиһазлау. Ш. Галиев, Р. Миңнулин, Р. Вәлиева, И.Юзиевның шигырь җыентыклары.

5 тема. К. Насыйри китапларыннан үрнәкләр. Аның педагогик эшчәнлеге.

Максат. К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге белән якыннан танышу.

*Җиһазлау.*Татар әдәбияты тарихы, К.Насыйри портреты, аның турында мәкаләләр.

6 тема. Тукай һәм музыка.

Максат. Бөек шагыйрьнең музыкага салынган әсәрләре «Шүрәле» балетыннан өзекләр тынлау. «Тукай аһәңнәре» китабындагы җырларга анализ. “Өзелгән өмид” мәкаләсенә лингвистик анализ, “Тәфтиләү” көе. .З.Хәбибуллин “Тукай” симфоник поэмасы

7 тема. Чит өлкәләрдә һәм чит илләрдә яшәүче зыялыларыбыз һәм галимнәребез.

Максат. (Америкада, Финляндиядә, Төркиядә, Япониядә һәм башка илләрдәге милләттәшләребезнең тормышы, эшчәнлеге) Күренекле Акчуриннар. Фән күгендәге йолдыз - Р.Сәгъдиев Беренче татар балерины Рудольф Нуриевларның тормышы, эшчәнлеге белән танышу.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

Җиһазлау. “Сөембикә”, “Мирас”, “Казан утлары”, “Мәгърифәт нуры” журналлары, газеталардан мәкаләләр, видеокассеталар

8 тема. Татар халык авыз иҗаты.

Максат. Мөнәҗәтләр, бәетләр, әкиятләр,мәкаль һәм әйтемнәр, риваятьләрне өйрәнү.

Җиһазлау. Татар халык әкиятләре 1 – 5 томнар, альбомнар, аудиокассеталар

9 тема. Идел буенда яшәүче халыларның теле һәм мәдәнияты.

Максат. Тугандаш (башкорт, чуаш, мари, удмуртлар) халыкларның мәкаль – әйтемнәре. Башкорт, чуваш, удмурт, мари халык әкиятләре. Удмурт шагыйре Михаил Петров, чуваш шагыйре Яков Ухсай, башкорт шагыйре Мостай Кәрим иҗатларын өйрәнү. Түбән Кама шәһәренең Дуслык йорты эшчәнлеге белән танышу.

Җиһазлау. “Удмуртское народное творчество”, “Чувашское декоративное искусство”, “Башкирское народно – музыкальное творчество”, “Түбән Кама” альбомнары, китаплар, карточкалар, видеопрезентация, ноутбук, видемагнитофон, интерактив такта, Михаил Петров, Яков Ухсай, Мостай Кәрим шигырь җыентыклары

10 тема. Халкыбызның җыр сәнгате, музыкаль җәүһәрләр.

Максат. Тормыш – көнкүреш җырлары. Лирик җырлары, такмаклар, такмазалар, уен җырлары, романсларны өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә. *Күрсәтмә материал.* Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

Җиһазлау. Татарское музыкальное творчество, Татар халык җырлары, Сак белән Сок бәете, «Сез яраткан җырлар» китаплары, видео, аудиозаписьләр.

11 тема: йомгаклау дәресе.

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Нинди уңышларга иреште к. Фикерләр алышу. Алдагы уку елына планнар. Үткәннәрне кабатлау.

3 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

№	Тема	Барлык сәгать	Теория	Практика	Аттестация формалары
1.	Кереш дәрес	3	3	-	Аралашу, тест сораулары
2	Тел – мәдәниятның коды	6	3	3	аралашу
3	Борынгы төрки әдәби тел Алтын Урда чоры әдәбияты, Казан ханлыгы чорына караган этнолингвистик материаллар	45	20	25	Үзлектән эш
4.	Шигырь төзелеше	45	15	30	Зачет эше
5.	Тылсым - сәхнә теле	28	10	18	Иҗади бәйге

6.	Халык әйтсә – хак әйтә. Татар халык иҗаты.Балалар фольклоры	43	18	25	Эшлекле уен
7.	Түбән Кама талантлары	16	10	6	Тест сораулары
8.	Татар композиторлары	30	10	20	Иҗади бәйге
9.	Йомгаклау	2	2		Реферат яклау
	Барлык сәгать:	216	89	127	

3 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

1 тема. Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре. Берләшмәнең планы белән танышу. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

2 тема. Рәсәй тарихыннан. Тарихымны мирас итеп. Күренекле шәхесләребез: Әбрар Кәримуллин, Ибраһим Нуруллин. Әдәбият һәм сәнгать чынбарлыгы.

Җиһазлау.”Әдәбият һәм сәнгать чынбарлыгы”, “Татары – этнос или этноним”китаплары, Газета материаллары, альбомнар

3 тема. Борынгы төрки әдәби тел. Татар теленең башлангыч үсеш чоры.

Идел буе төрки әдәби теле. Алтын Урда чорында татар әдәби теле. Әдәби телдә грамматик, морфологик нормалар.

Казан ханлыгы чорына караган этнолингвистик материаллар белән танышу. Татар халкының бу чордагы язмышы, сәнгате. Татар милли әдәби теленең лексик нормалары, фразеологик әйтелмәләр. Татар әдәби телен үстерүдә Тукайның роле.

Җиһазлау. “Тел – тарих көзгесе”, “ Те л – ил сагында” китаплары, журналлар, аудио – видео кассеталар, ноутбук.

4 тема. Шигырь төзелеше. Ритмик яңгыраш. Озын, кыска үлчәмдәге шигырьләр. Тел – сурәтләү чараларыны. Эпитетлар. Чагыштырулар. Сынладырулар. Метафоралар.Поэтик синтаксис. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

Җиһазлау. карточкалар, схемалар, төрле шигырь җыентыклары.

5 тема. Тылсымлы тел – сәхнә теле. “ Мәхәббәт тәүбәсе”. Драма, комедия, сатира әсәрләре. Татар театры . Драматург һәм режиссер К.Тинчурин итатына күзәтү. Театр яктылыкка, нурга илтә... Г.Камал иҗатына күзәтү.

Җиһазлау. Альбомнар. К.Тинчурин әсәрләре, пьесалар җыентыклары.
6 тема. Халык әйтсә - хак әйтә. Татар халык иҗаты. Мәкаль – әйтемнәр, ышанулар, юраулар.Әкиятләр. Балалар фольклоры уен – йола җырлары. такмаклар, такмазалар , ил турында җырлар лирик җырлар. Җырларның теле.
Җиһазлау. Татар халык иҗаты 1 – 5 томнар, җыр җыентыклары, аудиокассеталар
7 тема. Түбән Кама талантлары. Яшьләр авазы. "Илһам" эстрада ансамбле.
Җиһазлау. Альбомнар, видеокассеталар, китаплар, буклетлар.
8 тема. Татар композиторлары. С. Габәши мирасы. Р.Яхин, А.Монасыйпов һәм Ф. Әхмәдиев иҗатлары. С.Хәким сүзләренә җырлар. З.Хәбибуллин, Ә.Бакиров иҗаты. С. Садыйкова һәм Ә.Ерикәй иҗат дуслыгы. А.Ключарев һәм татар музыкасы.
Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г
Җиһазлау. Композиторларга кагылышлы мәкаләләр, аудиокассеталар, җыр җыентыклары, ноутбук, аудио – видеокассеталар, интерактив такта.
9 тема: йомгаклау дәресе.
Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.
Реферат яклау. Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Алдагы уку елына планнар. Үткәннәрне кабатлау.

4 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

№	Тема	Барлык сәгать	Теория	Практика	Аттестация формалары
1.	Кереш дәрес	3	3	-	Аралашу, мини- тест
2	Сәнгать аша – тормышка...Татар рәссамнары.	36	18	18	Аралашу, ижади эш
3	Шигърият баскычлары – Тел – матурлык ачкычы. Шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр	54	21	33	Ижади бәйге, практик эш
4.	Яшәү кыйбласы – әхлак һәм культура	27	9	16	Үзлектән эш
5.	Публицистик әсәрләр дөньясы. (парча, новелла, нәсер, мәкалә	21	6	15	Мини - тест
6.	Татар киносы	15	9	6	Карточкалар белән эш

7.	Серле йомгак	30	15	15	Мини - тест
8.	Сүз һәм музыка бердәмлеге	30	15	15	Иҗади эш
9.	Йомгаклау	2	2		Йомгаклау чыгышы
	Барлык сәгать:	216	98	118	

4 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

1 тема. Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре. Берләшмәнең планы белән танышу. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

2 тема. Сәнгать аша – тормышка. Язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, җырчылар, режиссерлар эшчәнлеге (Г.Бәширов, Т.Миңнуллин, Ф.Яруллин, М.Әгләмов, С.Садыйкова, М.Шәмсетдимнова, С., З. Садыйкова, М.Сәлимҗанов, Ф.Бикчәнтаев, З.Сәхабиева, Х.Тимергалиева, З. Фәрхетдинова). Татар рәссамнары. Х.Якупов, Ә. Фәтхетдинов.

*Җиһазла*у. “Сәхнә”, ”Мирас “, “ Идел”, “ Гасырлар авазы”“Культура”, “Татарстан”, “Казан”, “Музыка и время” журналлары. Газета материаллары, альбомнар, аудио – видеокассеталар, бу шәхесләрнең тормыш һәм иҗат юлы турында мәкаләләр, спектакьләрдән өзекләр.Авторларның альбомнары, картиналар, аларга кагылышлы мәкаләләр.

3 тема. Тел – матурлык ачкычы. Сөйләм культурасы. Әдәби телдә грамматик, морфологик нормалар. Язма һәи сөйләм телендә стильләр. Татар дикторлары Эльмира Хамматова, Инсаф Абдулла, Резедә Гәрәева.

Шигърият баскычлары. Т. Галиуллин, Юзеев, Р.Харис, Ф.Мөхәммәтова, К.Булатова иҗаты. Авторлар иҗатыннан үрнәкләр. Шигырьләрдәге тел – сурәтләү чаралары, ритмик яңгырашы, эпитетлар, чагыштырулар сынладырулар, метафоралар. Шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр һәм язучылар

Җиһазлау. Людмила Аланлы, Әлфия Сибгатуллина, Ралия Кәримованың җыентыклары, альбомнар. Шагыйрьләрнең эшчәнлегенә кагылышлы мәкаләләр, альбомнар, карточкалар, аудиокассеталар. “Телләр белгән – илләр гизгән”, “Тел – тарих көзгесе”, “ Тел – ил сагында” китаплары, журналлар, аудио – видео язмалар

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

Шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр һәм язучылар.

Җиһазлау. Людмила Аланлы, Әлфия Сибгатуллина, Ралия Кәримованың җыентыклары, альбомнар, мәкаләләр.

4 тема. Яшәү кыйбласы – әхлак һәм культура

Җиһазлау. “ Путь к прекрасному”, “По законам красоты”, “ Сокровища красоты”, “Музеи мира” китаплары һәм альбомнары, ауди – видео кассеталар

5 тема. Парча, новелла, нәсер, мәкалә (публицистик әсәрләр дөньясы)

“Мирас”, “Казан утлары” җурналлары, газета мәкаләләре, видеокассеталар

6 тема. Татар киносы. Мөселман дөньясы төшергән кинолента лар

Җиһазлау. Альбомнар, видоекассеталар,

7 тема. Серле йомгак. Халкыбызның күңел бизәкләре – кул эшләре. Музейлар эшчәнлеге. Экспонатлар ни сөйли? Шәҗәрәләр

Җиһазлау. Альбомнар,картиналар. Дөнья музейлары альбомнары видеокассеталар, аларга кагылышлы мәкаләләр, кул эшләре үрнәкләре (чигешләр, шәл - яулыклар, чокып һәм тукып ясалган эшләр

8 тема. Чит илләрдә яшәп иҗат итүче татар композиторлары. С. Гобәйдуллина, Р.Ахъярова. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

Күрсәтмә материал: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Миниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г

Җиһазлау. Композиторларга кагылышлы мәкаләләр, аудиокассеталар, җыр җыентыклары.

9 тема: йомгаклау дәресе.

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Йомгаклау чыгышы. Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Әдәби-драматик" өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү хакында таныклык бирелә.

ПРОГРАММАНЫҢ ПЕДАГОГИК-ОЕШТЫРУ ШАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ.

Программаның гамәлгә ашыруылы өчен кирәкле шартлар: уку процессының масатчанлыгы; балаларның дәресләргә системалы рәвештә йөрүе; табигый сәләтне этаплап үстерү; уку материаланың аңлаешлы булуы; балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу; һәрбер балага индивидуаль якын килү; дәресләрдә уңай психологик халәт тудыру.

Методик комплекслар:

информацион материаллар, карточкалар, дәресләр өчен кирәкле рәсемнәр, методик эшләнмәләр.

Программаның үтәлешен билгеләү һәм тикшерү өчен: тестлар, контроль күнегүләр, система һәм гомумиләштерүче таблицалар.

Программа төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру, укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыруны күздә тота.

Материаль-техник база:

Укучы урындыгы – 20 шт.;

Укучы өстәле – 10 шт.;

Укытучы өстәле – 1 шт.;

Укытучы урындыгы – 1 шт.

Дидактик материаллар (методик эшкәртмәләрдән, дәресләр план – конспектларыннан, практик дәресләргә методик күрсәтмәләрдән торган комплектлар), журналлар, буклетлар, альбомнар, карточкалар.

диагностика үткәрү материаллары: тестлар, дидактик уеннар, кроссвордлар.

Укыту практикасында видеотека материаллары кулланыла, болар төрле бәйгеләр (муниипаль, төбәкара, республикакүләм) вакытында төшерелгән чыгышлар. Бу материаллар “әдәби – драматик “ берләшмәгә йөргән укчыларның ирешкән уңышларына нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Программа балаларны укыту, иҗади яктан үстерү, тәрбия бирү аспектларының бердәмлегенә нигезләнгән.

Программаны тормышка ашыруның төп принциплары:

-баларның яшьүзенчәлекләре исәпкә алынган

-аңлылык принципы балаларның кызыксыну, аңлап эш итә белү дәрәҗәләре

Бәяләү материаллары

–бәйгеләрдә, конкурсларда катнашу, рефератлар яклау, тестлар, биремнәр эшләү программаны тиешле югарылыкта үзләштерүдә ярдәм итә.

Курс педагог белән берлектә төп күнекмәләрне һәм гамәли эшләрне, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүне күздә тота. Дәресләр балалар берләшмәсе өчен туры килә торган, *теоретик һәм практик дәресләр үткәрү өчен җайланылган.*

Программаны үзләштерү сыйфаты һәм нәтиҗәләге диагностикасы.

Үткәрү вакыты	***Үткәрү максаты***	***Аттестация һәм контроль формалары***
кереш контроль		
сентябрь	Балаларның үсеш дәрәҗәсен һәм аларның иҗади сәләтләрен билгеләү	Сораштыру, анкета, биремнәр, тест
агымдагы контроль		
декабрь	Укуда алга киткәннәрне барлау, укучыларда укуга карата җаваплылык һәм кызыксыну уяту	Биремнәр, тестлар, бәйге

арадаш контроль		
май	Укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. Укучыларда укуга карата җаваплылык һәм кызыксыну уяту.	Тестлар эшләү, реферат язу
Йомгаклау контроле		
май	Балаларның дүрт еллык уку матералын үзләштерүе.	Йомгаклау чыгышы

Педагогик мониторинг.

Программаны уңышлы үзләштерүнең нәтиҗәләрен системалы күзәтүмониторингы

Параметрлар	Критерийлар
Белем бирү нәтиҗәләре	Балаларның белем бирү прогаммасының эчтәлеген аңлавы. Белем һәм күнекмәләрнең төрлелеге. Предмет буенча белемнәрнең тирәнлеге. Балаларның практик үсеш һәм ижади нәтиҗәләре. Иҗат уңышларының төрлелеге (бәйгеләр, конкурслар, фестивальләр, фәнни – гамәли конференцияләр). Игътибарлылык, хәтер, кузаллау кебек гомуми күнекмәләрне формалаштыру һәм үстерү
Тәрбия бирү нәтиҗәләре	Үзеңне культуралы тота белү. Биремнәрне эшләгәндә пөхтә итеп эшләү, эш урынын тәртиптә тотарга тырышу.Башлаган эшне ахырына кадәр җиткерә белү.
Социаль - Педагогик нәтиҗәләр	Санитар-гигиена таләпләрен үтәү. Куркынычсызлык, иминлек кагыйдәләрен үтәү. Коллективта аралашу кагыйдәләре. Педагогка мөнәсәбәт.

Критериейлар күрсәткече түбәндәге дәрәҗәләр белән билгеләнә: югары, уртача, түбән. Мониторинг һәрбер бүлек материалы үтелеп беткәч үткәрелә.

Белем һәм күнекмәләрнең төрлелеге.

Югары:

-халкыбызның гореф – гадәтләрен, традицияләрен аерып күрсәтә ала,

-балалар әдәбиятының матур үрнәкләрен белә;

-сәхнәдә чыгыш ясаудан курыкмый;

-авзлар артикуляциясенең үзенчәлекләрен дөрес тоемлый ;

Уртача:

-сәхнәдә чыгыш ясарга әзер түгел ;

- халкыбызның гореф – гадәтләрен, традицияләрен авыр аера;
- авазларны бик үк дөрес әйтә алмый

Түбән:
- авазлар артикуляциясен тоемлый алмый;
  халкыбызныж гореф - гадәтләрен белми;
- сәхнәдән курка

Предмет буенча белемнәрнең тирәнлеге.

Югары:
- татар халкының милләт буларак кайчан оешуын аңлата ала ;
-татар әдәбияты узган тарихи юлны белә;

Уртача:
- татар халкының милләт буларак кайчан оешуын җиңел аңлата алмый ;
-татар әдәбияты узган тарихи юлның аерым этапларын гына аңлата ала;
